

“Ватаным Татарстан”газетасында Камил Сәгъдәтшиннын авыл нигә картая дигән мәкаләсенә тап булдым. Чынлап та шулай бара бит. Без дә сvнеп килгән авыллар турында язган идек. Язып кына хәл яхшырмый;авылны vзгәртергә кирәк – ә ничек...
Росстат мәгълvматларыннан кvренгән-чә, сонгы 15-20 елда ил буенча Рос-сиядә 19200 мәктәп, 5 меннән артык хастаханә, меннәрчә мәдәният йорты һәм башка бик кvп социаль объектлар “оптимальләштерелгән”, ягъни яшәvдән туктаган. Шул исәптән авыл халкына хезмәт кvрсәтvче 8400 хастаханәнен 5 меннән артыгы ябылуга дучар ителгән. Оптимальләштерv шаукымы Мордовияне дә әйләнеп узмады.      Кvп кенә авылларнын киләчәккә омет чыганагы булып хезмәт иткән мәктәпләр, балалар бакчалары, участок хастаханәләре, мәдәният йортлары һәм башка тор социаль объектлар бушап калды. Мәсәлән, Кадошкино районы Большие Поляны һәм Насакань Потьма авылларына бер фельдшер. Ул табибка ниләр кvрергә туры килә...vзе генә белә. Шулай һәрбер авылда. Һәм инде бу объектлар да ябылгач, Мордовия буенча ничә мен кеше, vзләре һәм гаиләләре очен яхшы тормыш шартлары булдырырга теләп, читкә китәргә мәжбvр ителде. Алар, 18-35 һәм олы яшьләр. Камил Сәгъдәтшин фикере белән килешәм: югары әзерлекле, белемле, кулларыннан теләсә нинди эш килvче яшьләр, эш һәм тиешле шартлар тудырылса, авылнын киләчәге була алыр иде.
Дорес, торле дәvләт программалары, Президент һәм республика житәкчеләренен кондәлек кайгыртуы нәтижәсендә бvген республика авылларында әледән-әле яна мәктәпләр, ФАП, ягъни авыл халкына медицина ярдәме кvрсәтv пунктлары, башка торле социаль объектлар да сафка баса. Әмма, туй узгач – думбра дигәндәй, кvп авылларда яшәргә кеше кимегәннән-кими барганда, бер туздырганны янә жыеп алу да жинел булмаячак шул. Бvген авыл жирлегендә vз урынын, vзенә нинди дә булса эш-шогыль тапкан 1000 яшь кешегә 760 бала һәм олкән пенсионер туры килvе дә хәлне шактый катлауландыра. Бу исә авылда эшләvче хезмәт кешесенен жилкәсенә тигән йок шәһәрдә яшәvчеләргә караганда ике тапкыр артыграк туры килә дигән сvз дә әле.
Авыл кешесенен гомер озынлыгы шәһәрдә яшәvчеләрнекенә караганда 2 елга кимрәк булу да уйландыра. Байтак кына авылларнын тенкәсенә тигән юлсызлык, авыл хужалыгында житештерелә торган продукциягә тиешле бәя булмау, житештерелгәнне вакытында сата алмау, хезмәт хакларынын чагыштырмача тvбән булуы, кайчагында анысынын да тоткарлануы һәм башка бик кvп торле социаль гаделсезлекләрнен нәтижәсе бу.
Ә бит топтән уйлап караганда, авылда яшәvчеләр шәһәрнекеләрдән кvпкә бәхетлерәк. Башкача булганда, язга чыгу белән момкинлеге булганнар авылга, дачаларга

ашыкмаслар иде. Һәрхәлдә, табигать кочагында сәламәтлеккә дә файдалырак, кvнеллерәк тә. Кечкенә генә жир кишәрлегендә кыш буена житәрлек итеп яшелчә, жиләк-жимеш vстерv дә гаилә бюджетына комачау итми.
Шулай булса да, авылда яшәvчеләрдән зар авазларын кvбрәк ишетергә туры килә. Аеруча яшьләрдән. Галимнәр әйтvенчә, авылда яшәvчеләрнен яртысыннан артыгы vз тормышыннан канәгать тvгел. Югыйсә бvген һәр авылда газы, уты, суы, кыскасы, бар нәрсә бар. Кvз алдында булган унай vзгәрешләрне санап та бетерерлек тvгел. Компьютер, кесә телефоны, интернет момкинлекләреннән файдаланып була. Белгечләр яшьләрнен vз тормышларыннан канәгать булмавын авылларнын киләчәгенә омет кими баруы белән дә анлата.
Камил Сәгъдәтшин белән мин дә килешәм. Сез, хормәтле «Юлдаш»ны укучыбыз, ничек уйлыйсыз; уйларыгыз белән уртаклашсагыз иде?

**Н.Хәлил**